ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында» 598-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты А.Ю. Егоров тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында» 598-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 27 сентябре
№ 66-VII ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутаты
А.Ю. Егоров
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясындагы 2 өлешенә (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2023, № 95 (I өлеш), «2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә» сүзләрен «2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарына карата 2027 елның 1 гыйнварыннан кулланыла» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләү шәһәр округлары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне яңадан бүлү срогын күчерү кирәклегенә бәйле.

2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә 2024 елның 1 гыйнварыннан шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләр җирлекләрнең, Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында яңадан бүленде. Шәһәр округлары өчен әлеге Законның үз көченә керү срогы кичектерелде, ул 2025 елның 1 гыйнварыннан башлана.

Шуның белән бергә ике Татарстан Республикасы шәһәр округында шәһәр төзелеше эшчәнлеге мәсьәләләре буенча килгән мөрәҗәгатьләр саны Татарстан Республикасы муниципаль районнарына караганда сизелерлек артык. Мәсәлән, 2023 елда Казан һәм Чаллы шәһәрләре муниципаль берәмлекләре башкарма комитетлары тарафыннан җир кишәрлекләренең шәһәр төзелеше планнарын бирү буенча 7 473 гариза каралган, төзелешкә рөхсәт алуга 2 478 гариза каралган һәм 788 мондый рөхсәт бирелгән, объектларны файдалануга кертүгә 1 299 гариза каралган һәм 472 мондый рөхсәт бирелгән, шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итү мәгълүмат системасыннан белешмәләр бирү турында 2 206 гариза каралган.

Татарстан Республикасы территориясендә торак төзелеше объектларын гамәлгә кертү планын, аның шактый өлеше шәһәр округларына туры килә, үз вакытында башкаруны тәэмин итү максатларында региональ дәрәҗәгә күчерүгә планлаштырыла торган вәкаләтләрнең Казан һәм Чаллы шәһәрләре өчен мөһимлеген игътибарга алып, закон проектында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне яңадан бүлүне Чаллы шәһәре өчен – 2026 елның 1 гыйнварына һәм Казан шәһәре өчен 2027 елның 1 гыйнварына кадәр кичектерү тәкъдим ителә.

**«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары исемлеге**

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының үз көчләрен югалтуын тану, аларны туктатып тору, үзгәртү яисә башкаларын кабул итү таләп ителми.

**«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына финанс-икътисадый нигезләү**

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән каплана торган өстәмә чыгымнарны таләп итми.